**Фаяз ДУНАЙ**

# ЯР ЧАЛЛЫ
**(Поэма)**

Чулман ярларына бу кирмәние
Кем салганын Тарих әйталмый,
Ерак дәверләрнең шаһитлары
Дөньялыкка кире кайталмый.
Тик хәтердә, тарих хәтерендә
Жуелмый бит асыл дәлилләр,
Безгә килеп җиткән ядкәрләрне
Тарих әле озын-озак сөйләр.
Чулман-Идел ага, ашыгып ага,
Ярларына хатирәләр кага,
Гүя аның алкын дулкыннары
Йөгерәләр киләчәккә таба...
Хатирәләр, ил-су ядкәрләре
Безнең өчен изге, кадерле.
Менәм тауга, төшәм су астына
Табармын күк серле каберне.
Бу кабердән Чаллы кирмәненең
Кораллары табылыр сыман,
Бакыр бер чүлмәктә Болгар илнең
Тәңкәләре тап булыр сыман.
Шәт, табармын Чаллы бичәсенең
Җәүһәр койган энже беләзеген,
Төшләремә керә Болгар кызы

Жемелдәтеп якут йөзеген.
Энже калфак аның башларында,
Зифа аяклары читекле,
Куе-бөдрә, парлы толымында
Затлы чулпылары челтери...

***

Яр Чаллы ул – Болгарның үз биләмәсе,
Шанлы илнең хак терәге булган,
Чулман-Нократ төбәкләрен багып,
Чикләрендә сак-каравыл торган.
Узып йөргән сәүдә кәрваннары
Затлы ташлар, бакыр, тоз төяп,
Болыннарда – җиләк, басуларда
Тары, бодай үскән күкрәп.
Яр Чаллы ул бөек Болгар илнең
Сунарчысы, балыкчысы булган,
Сусар, жофар, бурсык... нигъмәтләре,
Җәен, чөгә, корбан... – базар тулган!

***

Биләр йортка озатылган Яр Чаллыдан
Тере балык, кымыз, тире олаулары,
Көймәләр кәрваны белән тулып торган
Чулман суның култыклары, утраулары.
Яр Чаллының йомры, шома чуерташы
Аслык булган биналарның нигезенә,
Осталары балык, кош-корт сурәтләрен
Сырлаганнар тәрәзләрнең кәрнизенә.

Дүрт йөз гомер уяу кирмән өсләрендә
Моңлы азан яңгыраган иртәләрдә.
Ирләр илне саклый, хатын-кызлар
Тыгыз киндер тукыганнар җилкәннәргә...
Бер риваятьтә әйтелә: Булат Тимер!
Юл жаенда Яр Чаллыга килеп чыккан,
Яу кичкәндә Чаллы-суны адарынып,
Сәргаскәрнең ярсу атын яшен суккан!
Шуны шом-шаукымга юрап Булат Тимер
Яр Чаллыда кунак булмый, тизрәк киткән...
Яна Болгар исемен алган Чаллы кирмән,
Озак, имин, игелекле еллар үткән.
Агымсуларда агылып Чаллы илгә
Башкорт, удмурт күршеләре килә булган,
Яшь йөрәкләр никах белән кавыша торган,
Туйларына хак муллалар дога кылган.
Урманнарга, суларга бай бу халыклар
Ихлас белән кунакка еш йөрешкәннәр,
Шатлыкларын, эч серләрен бүлешкәннәр,
Бәла килсә, бер-берсенә булышканнар.
Уртак уен, уртак жырлар яңгыраткан
Су буйларын, жәнлек тулы урманнарны,
Азгын ут булып дөрләгән кызыгудан,
Көнчелектән урысның феодаль жаны...

***

Дулкыннар агыла алкынып,
Дулкындай агыла заманнар,
Казан ил өстенә Мәскәүдән
Яу килгән! –  дигән зур хәбәр бар.

Чаллыга яугирләр җыела,
Өермә бөтерелә Чаллыда:
Казанны якларга! Яңа яу
Кузгала туганнар хакына.
Көймәләр йөзалмый – октябрь,
Чулманны каплаган боз көбә.
Һай, вакыт сузыла, Чаллылар
Ат белән баруны хуп күрә.
Аргамак иярли яугирләр,
Кулларда – айбалта, кылычлар – билләрдә,
Гаскәрне җитәкли йөзбашлар,
Казанга ашыга очынып җилләрдә.
Юл авыр – баткаклык, урманнар,
Яңгырга кушылып боз ява,
Атларны томалый күк күбек,
Таядыр иярләр, киемнәр тозлана.
Һай, соңлап, барыбер, әй, соңлап
Казанга ирешә Чаллылар гаскәре.
Ай качкан болытлар астына
Күрергә куркынып мәхшәрне...
Казанда ут-төтен, кан ага
Елгадай урамнар тутырып,
Феодаль урыслар ду купкан,
Ханлыкның шөһрәтен хур кылып.
Кибетләр шыр калган, базар – буш,
Жимереп мәчетләр басканнар,
Аксакал картларны асканнар,
Балалар башын да чапканнар...
Чал тарих һич гафу кылмаслык
Фаҗига котырган бай Казан өстендә...

Һай, соңлап килделәр, әй, чыдап тормаслык
Хурлык бу Чаллылар өчен дә!
Гарьлекне йомарлап йөрәккә,
Үч-ачу дөрләтеп күкрәктә,
Мәскәүнең юлларын урыйлар,
Очраган мөртәтне турыйлар.
Кызганыч, яугирләр күп түгел,
Көч житми Мәскәүне урарлык.
Һай, ханлык җимерелгән,
туганнар җиңелгән,
Дин мәсхәр ителгән – ни хурлык!
Татарлар хәтерендә шул чактан
Юылмас кер калган урыска,
Аллаһмы, язмышмы каргаган –
Татарны чаптырган йомышка.
Дулкыннар агыла Чулманда,
Дулкындай агыла дәверләр...
Ил ары ил яулап тарихта
Көчәйгән насаралар, каферләр.

***

Ябырыла ятлар Чулман буйларына,
Басып ала басу, болыннарны,
Күп төбәктән куа татарларны,
Нәфес дигән чирнең чиге бармы?!
Мал-мөлкәтне ташый ят илләргә,
Хатын-кызны кол жария итә,
Жанын талап горур татарларның
Бау-богаулы озак еллар үтә...

Чукындыру... Диндә көчләү юк! – дип,
Дога укып үскән татарлар,
Гаскәр урап алгач авылларын,
Йортын баскач, кая качырлар?
Чукындыру... Бөтен Кама ягы
Төбәкләрен шул афәт баса,
Урыс патша әмере халыкларны
Тын алдырмый, бугазын кыса.
Шуңадыр да Чаллы якларында
Шактый ишле керәшен авыллары,
Сагыш булып яши керәшеннең
Бәгырен өзгән моңлы җырлары...

***

Дулкыннар агыла айкалып,
Актарыла Кама давыл чыкса,
Камадан да ярсу төбәк халкы
Илдә-көндә берәр фетнә купса!
Татарлар баш имәс, бил бирмәс
Яу чапкан еллар күп тарихта,
Иреккә өметен җуймаган
Халык ул, җиңелеп калып та...
Батырша ягында, Пугачев явында
Ин гаярь яугирләр – Чаллылар,
Дин хакы, азатлык хакына
Бер хәтәр һөҗүмнән калмыйлар.
Бәхтияр Канкайның орышта
Шоңкардан гайрәтле дуслары –
Каранай Моратов, Идеркәй Мәхмүтов,
Казагътан кушылган Дусали –

Яр Чаллы җирендә патшаның
Меңләгән гаскәрен юк итеп,
Халыкта ирекккә ышаныч уятып,
Киткәннәр тарихны балкытып.
Камада дулкыннар агылган,
Шаулаган кан белән кушылып,
Төбәктә зар-давыл иңрәгән
Көрәшне гомергә хуш кылып.
Каманың агышы – буыннар сагышы
Еллардан-елларга күченгән,
Татарны өметкә чумырып, алдалап
Хөр туфан – инкыйлаб көн килгән.
Чаллылар яңадан яр кыйнап,
Ярсулы дулкында чайкала,
Чайкала маяклар,
серлесе, ялганы –
Чулманга сыйныфлар каны ага...
Чаллылар төшенми маякның,
агымның,
Дулкынның кайсысын сайларга?
Кыйбла – томанда, Чаллылар меңәрләп
Баш сала, кан түгә яуларда.

Хөр еллар тиз уза – большевик
Диктаты ирекне тиз буа,
Зынжырлы, коймалы тормышка
Халыкны Сталин тиз куа...

***

Яр Чаллының сөзәк бер үрендә,

Чулман суның биек ярында,
Бу якларның гүя иң түрендә,
Хуҗа булып төбәк малына
Элеватор тора. Рәсәй салган
Чит ил осталары кулы белән.
Арзан хакка ашлык киптерәләр,
Капчык ташый шунда күрше-күлән.
Олау-олау ашлык ташый аңа,
Авызыннан өзеп төбәк халкы.
Казна – саран, ярлы игенчегә
Тиен белән түли икмәк хакын.
Элеватор Чаллыныкы түгел,
Совет чорында да – дәүләтнеке,
Бар, берәр пот борчак алып кара –
Үкенерсең үлгәненә тикле.
Баржалар күп суда – бу якларның
Бар табышын төяп алып китә,
Дәүләт – саран, балык тотудан да
Чаллы халкын күптән мәхрүм иткән.
Дәүләт шул ук, исеме генә чуар,
Җил-давыллы чорлар үзгәрсә дә,
Халык нужасына гамьсез казна
Керү ягын карый гел кесәгә...

***

Сөбханалла! Тарих шаярттымы,
Могҗизалы яңа таң аттымы?
Дөньялыкта насыйп язмышымы –
Яр Чаллыга капты дан ялкыны!

Фикрәт Таби атлы бер әрсез җан,
Татар илен бизәр ният белән,
Державаның хаким йортларында
Хокук, вәкаләтләр даулап йөргән:
«Кама краенда гигант завод –
Автозавод төзү – бездә җайлы!
Юллар җайлы бездә һәр тарафка,
Халык уңган безнең, җирләр – майлы...»
Милли төбәкләрнең күп табышын
Җыеп алып барган Мәскәү Үзәк
Малга хирыс. («Татар – юмарт халык».)
Нигә яңа басу йөрсен эзләп...
Риза, риза Мәскәү – «Татария
Билен бөгеп үзе сорап торгач,
Һәр төбәкнең әрсез юксылларын
Сыйдырырга үзе риза булгач.
Төзесеннәр, төзесеннәр әйдә,
Татария малга бай бит ул,
Татар халкы күптән безнең батрак,
Хәтер ягыннан да сай бит ул.
Телисеңме, урманнарын бирер,
Бирер юмарт елга-суларын,
Җаның теләгәнчә ауга йөре,
Басып яшә татар сылуларын...»
Мәскәү шулай фикер итте, диләр –
Һәм башланды гигант төзелешләр.
Чакыру бар:
КамАЗны бөтен ил төзи!
Кама ярларында бөек эшләр!...

***

«КамАЗны бөтен ил төзи!» – Яр Чаллыга
Илнең төрле төбәгеннән маршрутлар...
Яшел ут бир! – агыла состав-эшелоннар,
Ни генә юк трюмнарда! – причалларда
Чират көтә теплоходлар.
Аэропортның һава аланнары ачык!
«Варяг» – йөремсәкләр килә төркем булып.
Рюкзаклар, чемоданнар, контейнерлар,
Нәфесле өметләр килә юл тутырып...
Чал Тарих уйланып кабатлый:
– Гыйбрәт, сабак алыгыз сез
олылардан,
Шәһәрләрне дәверләр төзи,
Төбәкләрне гасырлар бизи....
– Юк! – диләр җиңнәрне сызганып –
КамАЗны төзербез – елларда!

***

... Болгар бабай Ватан иткән җирләргә,
Кодрак илхан дәрхән сипкән үрләргә,
Тургайлар гомер кичергән басуга,
Гектар ары гектарларны даулый-яулый
Һөҗүм кырына, әнә, тагын яу чыга.
КрАЗ-платформалардан йөгереп төшеп,
Бульдозер – ярсыган үгез – җир актара,
Рация килеп җитә, су баклары,
Бер кылый күз адрес элә җил капкага.
Штаб-вагон күченеп килә. Прораблар...
Геодезист төреп тоткан планнарын,

Бер басуга көпчәкле өйләр тезелә,
Комендант килә күтәреп юрганнарын.
Тәүге чокырлар казыла субайларга,
Катлам нинди? – лаборант кыз проба ала.
«Мәхшәр җитте, дөнья бетте, туганнар!» – дип,
Карт йомран оясыннан чыгып чаба.
Кич житүгә яшьләргә «пятачок» кирәк –
Монтер егет прожектор куя асып.
Бар канауны күзләп йөри бер мут кәҗә,
Шәһәр хуҗасы булам дип, тырт-тырт басып.
«МАЗ»лар, «ГАЗ»лар килеп җитә
бетон түяп, –
Әнә шулай,
Юл башлана яңа урам, мәйданнарга,
Биек йортлар күтәрелә,
яңа чакыру:
«Тәүге ачкыч, беренче ордер – уңганнарга!»
Рейхстагка байрак элгән
Фронтовик уллары
Эш белән теркәп калдылар
Житмешенче елларны.
Тик һөҗүм башка, ысуллар,
Горизонтлар кинрәк.
Эштә мактану күбрәк,
Аек акыл кимрәк.
«Рекорд»лар монда көн саен,
Тик алар даим түгел,
Кичә Геворгян макталса,
Салахов шаулый бүген...

«Хужалар»га ни аларга

Тик план гына тулсын,
Кичләрен сауналарда
Жария көтеп торсын.
Хисапны бирә беләләр –
Йортлар брак булса да,
Төзелгән цех асларында
Бәла посып торса да.
Чын кала булсын! дип йөргән
Бибишевларга көн юк.
«Варяглар» да мин-минлек зур,
Өс бөтен, тамаклар – тук.
Шуңадыр да салганда ук
Калага ямь иңмәде,
Бу – мөселман төбәге, дип,
Фәрештәләр килмәде.
Шул ук «хуҗалар» ун еллап
КамАЗда «майландылар»,
Аны бурычка батырып,
Ут чыгарып тайдылар...
Төзедек, ашыгып төзедек,
Партия каулап торды –
Төрле мөртәтләр кулыннан
Кыйбласыз кала туды.
Музыкаль шайтан туйлары,
Чиркәү көн дә «Д-о-оң!» килә
Калада азан аһәңе
Бик тонык ишетелә...

***

Эреп тамган кызлар керфегендә
Карга бураннары күптән инде,
Кошлар төяп, умырзая тотып,
Ничәнче яз килеп җиткән инде!
Урамнарда, бульвар, тыкрыкларда
Кара туфрак ефәк юрган кебек,
Жех корасы жирдән кырып-себереп,
Ташып торды елгыр шофер егет.
Ак калага ата-бабаларның
Буразнасы күчеп килде шулай.
Рәнжүе килде яшь буынга,
Бәхилләшеп, сулкылдады тургай...
Яшел калсын, имеш, яшьлек төсе –
Агач утырттык без өмә ясап,
Кошлар моңы сарган яшь чыршылар,
Ак каеннар саф-саф булып басты.
Бу куаклар хәзер дәүләр инде,
Җәйләр килгәч – җимешләре җитә,
Тик аяныч: купшы яшеллеккә
Чаллы кешеләре гамьсез үтә.
Өлкәннәрне күзлим, ник берәрсе
Шулар тирәсендә ял итсен, әй!
Пакь күзләрен багып куакларга
Ятсын икән берәр елак бәбәй...
Юк. Бизгәннәр, якын итүче юк,
«Варяглар»ның нәселләре юньсез,
Татар исемен таккан ирләрнең дә
Оныклары инде моңсыз, телсез...

Сәбәпләре совет шартларында
Имансыздан –

имансызлар үскән,
Бу афәтне заман тыя алмаган,
Закон – какшау, бозык җилләр искән...

* * *

Үзгәртеп кордык, дип, мавыктык,
Җимердек куәтле дәүләтне,
Өрфия «демократ» миражга
Алданып, югалттык кодрәтне.
Сер түгел, «КамАЗ»лар – шәп товар,
«КамАЗ»лар сатыла күп илгә.
Тик сәер шунысы: табыш аз,
Чаллылар тилмерә тиенгә.
Эшсезлек, эшсезлек Чаллыда,
Шөгыль юк тап-таза ирләргә,
Каланың казнасы саеккан –
Салымны җыярга кемнәрдән?
Карашка аклыдыр, төзектер,
Иркендер бу кала.
Тик анда иртә-кич килмешәк
Әтрәк-әләмнәр чайкала.
Чайкала наркоман, фахишә,
Караклар кемнедер сагалый,
Сакалы чыкмаган «яшь тәкә»
Яшь татар сылуын чамалый...

Урамда теләнче чат саен,
Чат саен сәрхүшләр чайкала... –
Мәскәүгә баш иеп, ашыгып
Төзедек без сине, и, кала!

Татарнын төсе дип әйтерлек
Бина юк, корылма калада,
Төзсезлек, мөртәтлек, денсезлек –
Кай якка борылып карама.
Нур инми, ямь керми, мал килми
Килмешәк жыелган бу илгә.
Бу жирне арулар егетләр
Ышансын, иярсен, я, кемгә?..
Яр Чаллы әлегә моң-зарлы
Бик ярлы, кыйбласыз кала шул,
Үз динең, үз телең имгәтеп
Мәхшәрле тарафка бара шул...

***

Поэма озын булса да
Сүзләр бетщрлек түгел. -
Матурлык тантанасына
Бик тә ашкына күңел.
Зур ГЭСлар төзесәләр дә
Чулман су үзгәрмәде,
Минем халкым үз иңендә
Ниләрне күтәрмәде?!
Шәт, гасырның яңасында
Болгар ил калкыр әле,
Яр Чаллы да аруланыр,
Кояшы балкыр әле...

1999 ел